**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ**

422000, Татарстан Республикасы, Арча ш., Совет мәйданы, 14
телефон:(84366) 3-00-33,факс: 3-14-33, e-mail: 16T.009@tatar.ru

# К А Р А Р

14.03.2016 № 12

**2016 елның 13 мартында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе **2016 елның 13 мартында** узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

"2016 елда Апаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 150 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | Акча күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирләү урыннарын карап тоту | - Апаз авылында зират коймаларын алыштыру;<br>-Апаз авылыннан 4 км төньяк-көнчыгышка таба урнашкан (элекке Шомбаш торак пункты)гамәлдәге зират коймасын төзү. | 30000<br><br>10000 |
| 2. | Су белән тәэмин итү | Кзыл-Игенче авылында кое ремонты | 8100 |
| 2 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшчәнлеге | Апаз авылы (Ленин ур., Тукай ур., Совхоз ур., Гагарин ур., Базар ур.)<br><br>- Пөшәңгәр авылы (В. Әһлуллин ур., Нагорный ур., Чапаев ур.) | 66100<br><br>66800<br><br>42000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | - Мирҗәм авылы (Мәскәү ур., Н.Сафин ур., Профсоюз ур.)<br><br>- Каратай авылы (Г. Камал ур., Һ. Такташ ур.)<br><br>- Хәсәншәех авылы (каты көнкүреш калдыклары җыелган урынга килү юлы) | 21000<br><br>111000 |
| | Барлыгы | | 355000 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә".

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 1445 референдумда катнашучы кертелгән;

референдумда катнашучылар саны 1419, бу 98,2 процент тәшкил итә;

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 1396 кеше тавыш бирде, бу 98,38 процент тәшкил итә;

«юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 23 кеше тавыш бирде, бу 1,62 процент тәшкил итә.

Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча районы Апаз авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган дип таныргa, ә референдум нәтиҗәләре гамәлдә дип таныргa.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә:

"2016 елда Апаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 150 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | Акча күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирләү урыннарын карап тоту | - Апаз авылында зират коймаларын алыштыру;<br>-Апаз авылыннан 4 км төньяк-көнчыгышка таба урнашкан (элекке Шомбаш торак пункты)гамәлдәге зират коймасын төзү. | 30000<br><br>10000 |
| 2. | Су белән тәэмин итү | Кзыл-Игенче авылында кое ремонты | 8100 |
| 2 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшчәнлеге | Апаз авылы (Ленин ур., Тукай ур., Совхоз ур., Гагарин ур., Базар ур.)<br><br>- Пөшәңгәр авылы (В. Әһлуллин ур., Нагорный ур., Чапаев ур.)<br><br>- Мирҗәм авылы (Мәскәү ур., Н.Сафин ур., Профсоюз ур.)<br><br>- Каратай авылы (Г. Камал ур., Һ. Такташ ур.)<br><br>- Хәсәншәех авылы (каты көнкүреш калдыклары җыелган урынга килү юлы) | 66100<br><br>66800<br><br>42000<br><br>21000<br><br>111000 |
| | Барлыгы | | 355000 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә".

3. Җирле референдумның гомуми нәтиҗәләрен Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Арча районы<br>территориаль сайлау комиссиясе рәисе | Б.И. Кадыйров |
| Татарстан Республикасы Арча районы<br>территориаль сайлау комиссиясе секретаре | Л.И. Нурмиева |